ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.11.2015 с. Кильдеево 1

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Советының
«2016 елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди
авыл җирлеге бюджеты турында»карары проекты буенча
гавами тыңлауларны билгеләү турында

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын яклау максатыннан 2016 елга Килди авыл җирлеге бюджеты проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының "Килди авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. "2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге бюджеты турында" Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2015 елның 03 декабрендә 10.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү срогы - 1 көн;

2.3. Үткәрү урыны - Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында Килди авылы, Центральная ур., 16 йорт;

2.4. Фикер алышкан мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр язылырга мөмкин булган адрес - Килди авылы, Центральная ур., 16 йорт Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре Лёвочкина Н.Н. (Эш көннәрендә - 8.00 дән 16.00 гә кадәр);

2.5. гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү срогы - 2015 елның 30 ноябренә кадәр (тел 34-7-41).

3. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Советының "2016

елга Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге бюджеты турында" карары проекты буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге Карарда билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

3.2. Гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Советына гавами тыңлаулар беркетмәсе, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук Килди авыл җирлегенең 2016 елга эшләнеп беткән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проектын тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны, Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Советы карары проектын "2016 елга Килди авыл җирлеге бюджеты турында" Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Килди авыл җирлеге башлыгы В. М. Бурдин